ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22. 11. 2022 г.Лениногорск № 1194

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 8 ноябрендәге 1123 номерлы карары нигезендә расланган 2022 елның 16 ноябрендәге 1172 номерлы редакциядә) махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашып һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаиләләренә ярдәм итү чаралары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, мобилизацияләнгән гражданнарның (махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның) гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашып һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаиләләренә ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 8 ноябрендәге 1123 номерлы карары нигезендә расланган 2022 елның 16 ноябрендәге 1172 номерлы редакциядә) махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашып һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаиләләренә ярдәм итү чаралары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Түбәндәге эчтәлектәге 6 пункт белән тулыландырырга:

«6. Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан фитнес үзәкләре, спорт клублары һәм секцияләр коммерцияле оешмаларына махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар балаларын һәм махсус хәрби операциядә катнашып һәлак булган (үлгән) гражданнар гаиләләрен спорт үзәкләренә, клубларга һәм секцияләргә йөрү өчен түләүдән азат итәргә тәкъдим итәргә».

2. Әлеге карарның гамәли көче 2022 елның 21 ноябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.leninogorsk.tatarstan.ru) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), вакытлы матбугатта – «Лениногорские вести» газетасы аша халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

И.Р. Хәйбрахманов
5-44-72